**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Зур Тигәнәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

10 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 10 ноябрендә «2020 елда Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итүгә:

- Зур Тигәнәле авылында авыл эчендәге юлларга таш җәю, төзекләндерү һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы?

ӘЙЕ КАРШЫ"

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 416 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 209 кеше.

Халык җыенында катнашучыларның үзара салым кертү күләмен 400 сумнан 500 сумга кадәр арттыру турындагы тәкъдимен исәпкә алып, халык җыенында катнашучы гражданнарның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 198 кеше,

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 11 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Зур Тигәнәле авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен - вәкаләтле дип танырга.

2. "2020 елда Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итүгә:

- Зур Тигәнәле авылында авыл эчендәге юлларга таш җәю, төзекләндерү һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы?

ӘЙЕ КАРШЫ"

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты

бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 нче йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы С.Җ.Әхмәтҗанов